БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ
Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29 май 2020 ел № 244

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының 2019 елгы бюджет үтәлеше турындагы хисапны раслау хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексына, Татарстан Республикасы Бюджет кодексына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында бюджет процессы турында Нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының 2019 елгы бюджет үтәлеше турында хисапны керемнәр буенча 1013410,68 мең сум күләмендә һәм чыгымнар буенча 1019096,35 мең сум күләмендә, чыгымнарның керемнәрдән 5685,67 мең сум күләмендә артуы (Балтач муниципаль районы бюджеты кытлыгы) һәм түбәндәге күрсәткечләр белән расларга:

әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә керемнәр төрләре, керемнәр подвидлары кодлары, дәүләт идарәсе секторының бюджет керемнәренә карый торган операцияләр классификациясе буенча Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты керемнәре;

әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә бюджетлар керемнәре классификациясе кодлары буенча Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты керемнәре;

әлеге карарның 3 нче кушымтасы нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы буенча Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты чыгымнары;

әлеге карарның 4 нче кушымтасы нигезендә бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты чыгымнары;

әлеге карарның 7 нче кушымтасы нигезендә максатчан статьялар (дәүләт һәм муниципаль программалар һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре буенча Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты чыгымнары;

әлеге карарның 5 нче кушымтасы нигезендә бюджетлар кытлыгын финанслау чыганакларына карый торган дәүләт идарәсе секторының операцияләре классификациясенең бюджетлар кытлыгын финанслау чыганаклары төркемнәре, подгруппалары, статьялары, төрләре буенча Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары;

әлеге карарның 6 нчы кушымтасы нигезендә бюджетлар кытлыгын финанслау чыганаклары классификациясе кодлары буенча Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары.

2. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Балтач муниципаль район башлыгы,
Балтач район Советы рәисе — Р. Р. Нотфуллин